СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

28.12.2020 № 5/4

На №_________от_____________

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы милегендә булган мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль милекне (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2017 елның 27 мартындагы 13/11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларның «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль законга һәм ярдәм алучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрын формалаштыру максатында «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль законның 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 8 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль законда каралган ярдәм чараларын алу хокукын гамәлгә ашыру максатында, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы милегендә булган мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль милекне (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2017 елның 27 мартындагы 13/11 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга» сүзләреннән соң «шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга» сүзләреннән соң «шәхси эшмәкәр булмаган

һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар» (алга таба – махсус салым режимын кулланучы физик затлар) сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы милегендә булган мөлкәт исемлегенә кертелгән, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән муниципаль милекне (җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү тәртибендә:

исемендә «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга» сүзләреннән соң «шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга» (алга таба – махсус салым режимын кулланучы физик затлар) сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга» сүзләреннән соң «махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары» сүзләреннән соң «махсус салым режимын кулланучы физик затлар» сүзләрен өстәргә;

11 пунктта «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына» сүзләреннән соң «махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә;

12 пунктта «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына» сүзләреннән соң «махсус салым режимын кулланучы физик затларга» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, финанслар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев